Бүгенге санда:



Җылләткеч каналлар... җилне яратмый. 2 бит.


# Дуслык
Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Чәршәмбе 4 февраль 2015 ел

№ 7 (10536)


**5 февральгә һава торышы:** болытлы һава; урыны белән явым-төшем; юнәлеше үзгәрүчән җил, 3-4 м/с; температура көндез 0°С, төнлә -4°С

## *Абзац-информ*

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

### ОЧРАШУ ҮТТЕ

Узган атнада АТП бинасында коммуналь службалар вәкилләренең ТР МВДсының Экстремизмга каршы тору үзәге начальнигы Марсель Закиров белән очрашуы булды. Ул оператив хәл, экстремизмга каршы эш буенча ел нәтиҗәләре һәм 2015 елдагы планлы чаралар турында фикер алышуга багышланды.

### НАМУСЛЫ ХЕЗМӘТ БӘЯЛӘНДЕ

Тимер юл станцияләре эшен оештыру буенча Түбән Кама үзәге оешуның 5 еллыгына багышланган чарадан нурлатлылар да бүләкләр белән кайттылар. Нурлат станциясе буенча кизү Татьяна Спиридонова үзәк җитәкчелегенең Мактау грамотасы, ә поездлар тезүче Виталий Абрамов истәлек бүләгенә лаек булды.

### ДӘҮЛӘТ БҮЛӘГЕНӘ ИЯ БУЛДЫ

"Гармония" халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең социаль хезмәткәре Татьяна Бураева Россиянең "Социаль хезмәт өлкәсе отличнигы" күкрәк билгесе белән бүләкләнде. Аңа әлеге хөкүмәт бүләген 30 гыйнварда Татарстан Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының йомгаклау коллегиясе утырышында тапшырдылар.

### КАЗАНДА ДА КАУШАМАГАН

Казанда физкультура буенча узган республика олимпиадасында Егоркино урта мәктәбенең XI сыйныф укучысы Юлия Осипова II урын алган. Юляны олимпиадага укытучысы Александр Ендиряков әзерләгән.

### СЫЙНЫФ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ ЯРЫША

Кичә Нурлатта "Ел сыйныф җитәкчесе – 2015" республика конкурсының муниципаль этабы үтте. Анда барлыгы 10 педагог көч сынашты.

# Килегез, кошкайларым...

## 3нче мәктәпнең 8нче сыйныф укучылары "кошлар ашханәсе"ндә



Автор фотосы

**Суык көннәр – кош-корт, урман җәнлекләре өчен сынау чоры. Бу көннәрдә алар кешеләр ярдәменә аеруча мохтаҗ.**

Шәһәрнең 3нче мәктәбенең алма бакчасы бу көннәрдә чып-чын "кошлар ашханәсе"нә әверелә. Түбә куеп, уңайлы итеп ясалган җимлекләр янында чыпчык, песнәк кебек вак кошлар чыр-чу килә. Саесканнар да мәктәп ишегалдын үз иткән, быел хәтта кечкенә генә тукран да килеп ияләшкән әле, җепкә элеп куелган терлек маен аеруча яраткан, мавыгып фотообъектив белән янына ук килеп җитүебезне дә сизми калды хәтта. Жимлек эленгән һәр агачка сукмакларга кадәр көрәп торалар, шуннан узып йөрүче шәһәрлеләр дә гадәтләнгән – кошларга дигән бөртек, ярма, ипи кисәкләрен сала калдыралар. Мәктәп укучылары исә "ашханә"ләрендә ел да шулай кошларны сыйлый, биредә Татьяна Чибидина җитәкчелегендә эшләп килүче экологик бергәлеккә йөрүче балалар исә анда аеруча еш була. Узган елда республикада "Эколидер" бәйгесе җиңүчеләре булып танылулары да әнә шулай табигать турында даими кайгыртып торулары нәтиҗәсе. Быел әнә 8нче сыйныф укучысы Ксения Соснова экология буенча район олимпиадасында җиңү яулаган, бу көннәрдә республиканыкына әзерләнә.

Хәер, бу көннәрдә йорт ишегалларында да сый белән тулы җимлекләргә еш юлыгасың. Әнә, Гагарин урамының 8нче йортында яшәүчеләр үз ишегалларына пластик шешәләрдән уңайлы итеп җимлекләр ясап тулы бер "ашханә" булдырган. Шунда ук эре хәрефләр белән "Юл харчевнясы ачык" дип язып та элгәннәр. Бусы тирә-күршеләр дә җимлекләр яныннан битараф узып китмәсен өчен эшләнгәндер, мөгаен. Хәер, җимлекләре җимнән сыгылып тора, тирәсендә бер көтү кош – димәк, биредә олы җанлы, игелекле кешеләр аз түгел. Коры җим белән бергә кер җебенә тигез итеп ит-май кисәкләренә кадәр элгәннәр. Бусы кышын кошлар өчен чын "деликатес" инде. Бары кошларны тозланган, ысланган ит-май белән сыйларга ярамавын гына онытмаска кирәк.

Суык көннәрдә урман җәнлекләрен исә район аучылары кайгыртып тора.

- Урманнарда кабан дуңгызлары, пошиларны ашату өчен махсус мәйданчыклар бар. Кабан дуңгызлары өчен даими рәвештә бөртек, ә пошиларга – агач ботаклары, кайрылары салына, җәйдән әзерләнгән минекләр эленә, һәр җирдә тоз куела, - ди районның баш аучысы Ренат Мостафин. – Урман җәнлекләрен ашатуның үз кагыйдәләре һәм таләпләре бар, аучылар аларны яхшы белә һәм шуларга нигезләнеп эшли. Суыклар вакытында исә мондый биотехник чаралар никадәр җәнлекне үлемнән алып кала.

Календарьда кышның соңгы ае кереп бара. Күпләр көннәр җылыту белән кошлар һәм җәнлекләр үзләренә җимне тизрәк таба дип уйлап ялгыша. Кыш азагы кошлар өчен иң авыр чор санала һәм статистик мәгълүматларга караганда, суык көннәрдә кош 6 сәгатьтән артыграк ашамый торса, үләргә мөмкин икән. Димәк, гади генә җимлек ясап куеп, кошларга җим сибәргә һич тә соң түгел әле.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

КӨН КАДАГЫНДА

# Финанс алдауларыннан зыян күрүчеләр бар

Бушлай сыр тәбедә генә була, дип күпме генә сөйләмәсеннәр, аны татып карарга теләүчеләр табыла тора. МВД бүлеге мәгълүматларыннан күренгәнчә, "Кредит үзәге" кертемчеләре һәм заемчылары белән дә шулай килеп чыга. Үзәкнең төп офисы Казанда, алар белән ТР МВДсы шөгыльләнә хәзер. Нурлатта да әлеге кредит подразделениесе бар иде. Бер пенсионер ханым бирегә 100 мең сумлап акчасын китерә. Башта еллык 36 процент исәбеннән, аннан тагы да күбрәк табыш ала. Үзәккә 2 миллион сум бирүчеләр дә табыла. Әмма хәл үзгәрә. МВД бүлегенең өлкән тикшерүчесе Ләйсән Камалетдинова әйтүенчә, үзәкнең гамәлләреннән җиде нурлатлы зыян күргән.

– Тикшерү бүлегендә "Кредит үзәге"ндә акчалар урлау факты буенча ачылган җинаять эше бар. Оешма халыктан 36, 54, хәтта 108 кебек югары процентларга акчалар кабул итә. Бирегә баштарак килүчеләр ниндидер файда алалар да. Ә менә 2013-2014 елларда пирамида какшый башлый. Моннан зыян күрүчеләрнең күбрәк тә булуы ихтимал әле. Үзәктән кредит алучылар белән ниләр булып беткәнлеге әлегә билгеле түгел. Үзәкнең архивы аның безнең халык арасында шактый популяр булуын раслаучы документлар белән шыплап тулган. Бу популярлыкның нәтиҗәсе исә тикшерүдән соң һәм суд карары буенча билгеле булачак. Әлегә бер хакыйкатьне раслап була: тир түгеп тапкан акчаларыгызны ышанычсыз кулларга бирмәгез, төрле шикле кредитлар алудан да сакланыгыз.

Башка бер финанс пирамидасы нәтиҗәсендә дә 60лап нурлатлы зыян күргән. Аны оештыручылар, җиңел акчалар вәгъдә итеп, клиентларны кредит алырга һәм, янәсе, тиз арада каплау өчен акчаны үзләренә бирергә күндерәләр. Тик менә могҗиза гына булмый кала, акчалар берничек тә үсеп китә алмый.

**Валентина ВАФИНА**

**БЕЛЕШМӘ**

**Кредит оешмаларыннан һәм финанс алдауларыннан зыян күрүчеләрнең МВДның Нурлат районы бүлегенә килүләрен сорыйлар (кабинет 3-03, тел.: 2-46-36). Үзегез белән паспортыгыз, акчалар түләү квитанцияләренең, шәхси сакланмалар тапшыру турында килешүләрегезне алыгыз.**

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

ҖӘМГЫЯТЬ

## Нурлатлылар тәҗрибә уртаклашты

**Узган атнада балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе Нурлат районында тәрбиягә бала алып үстерү буенча эш тәҗрибәсен өйрәнде. Комиссия рәисе, ТР Премьер-министры урынбасары Васыйл Шәйхразиев бу эшне барлык татарстанлыларга үрнәк дип атады. "Уңай тәҗрибәне өйрәнү белән беррәттән, сезгә ярдәм кулы сузарга да әзербез, - диде Васыйл Гаязович шәһәр Мәдәният сараенда узган киңәшмәдә. – Районның олы йөрәкле җитәкчеләре булуы – үзе зур нәрсә".**



Автор фотосы

ВАНЧУРИННАР ГАИЛӘСЕНДӘ ӨСТӘЛНЕ ҺӘРЧАК МУЛ ИТЕП ӘЗЕРЛИЛӘР

Нурлатта әлеге юнәлештә район башлыгы, җитәкчеләр һәм гади халык бер команда булып эшли. Әнә, район башлыгы Равил Кузюровка бу көнне "Ата-ана йорты" клубының мактаулы әгъзасы исеме бирелде. ТР Дәүләт Советы депутаты, "ТНП-Зүзәйнефть" җәмгыяте генераль директоры, җәмәгать инспекторы Шамил Яһудин һәм башка җитәкчеләр белән дә мактана ала Нурлат районы.

- Татарстанда мондый хәйриячеләр булмаган районнар да бар, - диде ТР Премьер-министры урынбасары. – Игелекле эшләр алга таба да дәвам итсен иде.

Тәрбиягә бала алып үстерүче авыл буларак, бу эш 2008 елдан бирле нигездә районның ике – Мамык һәм Түбән Чаллы авылларында алып барыла. Мамык авылында гына да бүген 14 гаиләдә 43 тәрбиягә алынган бала үсә. Шөкер, райондагы бер генә бала да дәүләт учреждениеләренә урнаштырылмаган. 2006 елда коррекцияләүче интернат-мәктәптә ятимнәр төркеме бетерелгән. Узган ел гына да районга илебезнең төрле шәһәрләреннән 56 сабый кайткан . Бу эш белән нигездә районның "Ата-ана йорты" клубы вәкилләре шөгыльләнә. Клубта бүген барлыгы 165 гаилә исәпләнә. Тәрбиягә бала алып үстерүче Мамык авылының кураторы, клуб җитәкчесе Оксана Ванчурина әйтүенчә, аларның иң мөһим бурычы – тәрбиягә алынган балалар һәм балалар йортларыннан, приютлардан бала алып үстерергә теләүче кандидатлар белән эшләү. Моннан тыш, тагын бер юнәлеш – хәйриячелек. Хәйрия концертлары һәм ярминкәләр үткәреп, алар 2012 елда тәрбиягә алынган кызга операциядән соң тернәкләндерүдә ярдәм күрсәткәннәр. Бу хакта Мамык авылының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча җәмәгать комиссиясе утырышында хәбәр ителде.

Үзләренең 2 балалары янына тагын 10 сабыйны сыендырган Оксана һәм Сергей Ванчуриннар гаиләсе бүген гөр килеп яши, яңа өйгә күченгәннәр. Әле күптән түгел генә ике торак булмаган бинаны сатып алып, шуның берсен иркен йорт итеп үз көчләре белән ремонтлап та чыкканнар. Бүген 6 бүлмә һәм җылы санузелы булган иркен йортта һәр сабыйның эти-әнисе, үз почмаклары, абый-сеңелләре бар.

– Балалар көннән-көн алга бара, - ди хуҗабикә, җитәкче, фермер һәм солдат әнисе Оксана Ванчурина. – Армиядән кайткан улыбыз да, әле бакчага йөрүче сабыйлар да, мәктәп яшендәгеләр дә бар. Алар янына дуслары да җыела. Шуңа да йортыбызны зурайтырга булдык. Һәр баланың үз почмагы булсын, дидек. Икенче бинада балалар өчен уен, спорт залы һәм республика күләмендә беренчеләрдән булып оешкан "Ата-ана йорты" клубының утырышларын үткәрү урыны ясарга җыенабыз.

Әлеге гаиләдә һәркемнең үз шөгыле. Иң мөһиме, бала эш һәм спорт белән мәшгуль булырга тиеш, дип саный гаилә башлыгы Сергей. Ванчуриннар гаиләсе үз эшләрен булдырганнар. Бүген үзләренең 40 гектар җирләре, 2 тракторлары һәм 29 баш мөгезле эре терлекләре бар, моннан тыш, сарык һәм тавык – чеби үрчетү белән мәшгуль алар. Балалар кул эшләре белән шөгыльләнәләр. Алгы көнгә планнар белән уртаклашырга яратмый Ванчуриннар гаиләсе.

– Иң мөһиме, сәламәтлек булып, балаларны аякка бастырасы, укытасы, һөнәрле итәсе, олы тормыш юлына бастырасы бар, - диләр алар беравыздан.

Республика комиссиясе тәрбиягә бала алып үстерүче гаилә династиясе Галичиннарда да кунакта булды. Әлеге өлкәдә 9 еллап гаилә стажы булган Марина һәм Владимир гаиләсендә тәрбиягә алынган 17 бала һәм 11 онык исәпләнә. Гаилә бергәләп түгәрәк өстәл артына җыелганда, 30дан артып китәләр икән. Әлеге династиянең үзенчәлеге шунда – биредә үз эти-әниләре, соңрак опекуннары да баш тарткан балаларны тәрбиягә алалар, тагын да әһәмиятлесе – гаиләдә тәртип бозарга яратучы балаларны аякка бастыралар. Галичиннар гаиләсендә балаларны хезмәткә кызыксындырып тарта беләләр. Үз тырышлыклары белән буа буып куйганнар, үз куллары белән ясалган мини-техникалары, спорт мәйданчыгы, беседка һәм пляжлары да комиссия әгъзаларында зур кызыксыну уятты. Һәр ике гаиләдә дә балалар авыл тормышында "кайнап" яшиләр. Аларда тәрбия хезмәт аша оештырылган. Араларында спорт буенча уңышларга ирешүчеләр дә бихисап. Һәр ике гаилә балалары арасында механик, тракторчы һөнәрен үзләштерергә теләүчеләр җитәрлек. Ә мондый белгечләр авылда гына түгел, шәһәрдә дә кирәк. Очрашу барышында авыл турында сөйләгәндә, үз гаиләләрен тапкан балаларны торак пунктта калдыру турында да сүз булды.

ТР Премьер-министры урынбасары Васыйл Шәйхразиевның Нурлатка визиты барышында делегация "Ледок" Боз сараенда да булды. Биредә ТРның хоккей федерациясе дирекциясенең башкарма директоры Кирилл Голубев һәм башка рәсми затлар катнашында ТР һәм районда хоккей үсеше хакында түгәрәк өстәл утырышы үтте. Биредә үк кунаклар фигуралы шуу түгәрәгенә йөрүче балалар һәм аларның тренеры белән дә аралаштылар. Республика делегациясенең Нурлатка визиты шәһәр мунчасы төзелешен карау белән тәгәлләнде. Васыйл Гаязович райондагы эшлекле җанлылык һәм активлыктан канәгать калды.

**Зилия ӘКСАНОВА**

### САННАР ҺӘМ ФАКТЛАР

**Республикада барлыгы 765 мең 838 бала исәпләнә. Шуларның 11 мең 896сы ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм.**

### ХӘБӘРЛӘР

## МӨРӘҖӘГАТЬЛӘР ИГЪТИБАРСЫЗ КАЛМАЯЧАК

**Узган атнада 4 нурлатлы үзләрен борчыган сораулар белән ТР Дәүләт Советы депутаты, "Бердәм Россия" партиясе рәисе Дмитрий Медведевның төбәк иҗтимагый кабул итүе бүлмәсе җитәкчесе Татьяна Воропаевага мөрәҗәгать итте.**

Кабул итүгә килүчеләрне нигездә яшәү шартларын яхшырту, торак-коммуналь хуҗалык тармагына кагылышлы сораулар борчый булып чыкты. Ә менә нурлатлы Татьяна Әхмәтҗанова Иске Иглай авылына юлның торышыннан зарлана. "Юл булмау зур кыенлыклар тудыра. Бүгенге көндә авылда мәктәп яшендәге 8 бала бар, алар күрше авылларга йөреп укый. Юл булмаганлыктан, мәктәп автобусы да йөри алмый", - диде ул.

Татьяна Әхмәтҗанова әлеге мәсьәлә белән төрле инстанцияләргә мөрәҗәгать иткән икән. Районның рәсми сайты аша "Бердәм Россия" партиясенең җирле бүлекчәсендә кабул итү үткәрелүен белеп, Татьяна Васильевнага да килгән. Кабул итүдә район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллинның катнашуы исә сораугa урында ук ачыклык кертергә ярдәм итте – юлга вак таш җәю быелга планлаштырылган.

Кабул итү азагында исә Татьяна Воропаева бер генә мөрәҗәгать тә игътибарсыз калмаячак, дип белдерде.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

## МӘКТӘПЛӘР ГАРИЗАЛАР КАБУЛ ИТӘ

**2 февральдә районда балаларны беренче сыйныфка алу өчен гаризалар кабул итү башланды.**

Быел гаризалар ике этапта кабул ителәчәк. Мәктәпкә беркетелгән микрорайоннарда яшәүчеләр өчен ул 30 июньгә, башкалар өчен 1 июльдән 5 сентябрьгә кадәр барачак (буш урыннар булган очракта). Хәзер баланы беренче сыйныфка кабул итү буенча гаризаны мәктәпкә шәхсән үзең барып кына түгел, ә дәүләт хезмәтләре порталы аша да биреп була. "Образование" бүлегендә гариза формасы һәм укыту шартлары буенча тиешле мәгълүматны алырга мөмкин. Ата-аналар шулай ук гаризаларны карау нәтиҗәләрен дә күзәтеп бара ала. Гаризалар кабул итү барышы турында без шәһәр мәктәпләренең берсендә кызыксындык.

– Быел беренче сыйныфка 75 бала алып, 3 параллель комплектларга планлаштырабыз, – ди 4нче мәктәп директоры урынбасары Алсу Газизова. – Хәзергә 27 гариза керде. Ата-аналар гаризаларны асылда электрон юл белән бирә. Класслар комплектлануга, әзерлек дәресләре башланачак. Коллективка әзерлекләре төрле дәрәҗәдәге балалар килүен истә тотып, киләчәктә яхшы укучы һәм артта калучыларга бүленеш килеп чыкмавына аерым игътибар биреләчәк. Моның өчен балалар белән психолог та эшләячәк.

**Светлана ИГНАТЬЕВА**

ҖЫЕННАР

## Бурычларның яңалары куелды

Узган якшәмбе көнне авылларда гражданнар җыеннарына нокта куелды. Быелгы җыеннарның иң зур һәм нәтиҗәлелеккә китергән үзенчәлеге шунда булды: ул сөйләшү үзәгенә узган очрашуларда күтәрелгән сорауларның үтәлешен тикшерүне куйды. Шул рәвешле халык үзләрен борчыган сорауларның җилгә очмавын, ә район җитәкчелеге кайгыртуында булуын гамәлдә тойды. Район башлыгы Равил Кузюровның һәр очрашуда үзе катнашуы һәм службалар җитәкчеләреннән дә шуны таләп итүе җыеннарның шулай ук уңышын тәэмин итте. Өстәвенә, һәр авыл җирлегендә халык үтенече буенча башкарылган эшләр дә бар иде, үтәлмәгәннәренең сәбәбе ачыкланды, яңа сроклары билгеләнде, һәм бу да халык тарафыннан аңлап кабул ителде. Сөйләшү барышында күп авылларга хас уртак проблемалар да ачыкланды. Әйтик, быел район башлыгы участок уполномоченныйларына авылларда ялган аракы сатучыларга карата кырыс җәза күрелергә тиешлеген катгый таләп итеп куйды. Чулпан, Богдашкино, Бикүле кебек авылларда теркәлмәгән иске йортларның күп булуы уңаеннан прокуратурадан хокукый нигезле нинди чара күрергә мөмкин булуы турында мәгълүматый ярдәм күрсәтүләрен сорады.

–Кибетләрдә бәяләр коточкыч артты,–дигән борчулы сигналлар да эзсез калмады: дүшәмбедән коммерция кибетләрендәге бәяләргә мониторинг үткәрелә башланды. Авылларның инфраструктурасын яхшырту буенча алда торган эшләр дә кызыксындырды авыл халкын, мәгълүматлар исә бу уңайдан масштаблы эш алып барылуын күрсәтте. Әйтик, Равил Кузюров Андреевка, Богдашкино кебек авылларда суүткәргечләр сузу һәм сыйфатлы су булдыру ниятеннән районда су чыганакларын өйрәнү буенча геологик эзләнү эшләре алып барылуын хәбәр итте. Фәнни нигезләү алганнан соң эшнең техник ягына күчү генә максатка ярашлы булуы бераүдә дә шик тудырмады. Гомумән, очрашуда катнашучылар өчен район халкының тормыш дәрәҗәсен яхшырту, өстәмә эш урыннары булдыру җәһәтеннән сәнәгать паркы ачу, газобетон эшләнмәләр, рапстан май сыгу, нефть сервисы предприятиеләре эшли башлау, сугым урыны булдыру, әзерләүләр конторасы эшен торгызу, ит комбинатын эшкә җибәрү һ.б. кебек ниятләр дә шатлыклы хәбәрләр булды. Район башлыгы авыл халкының эшлекле активлыгы хупланачагын да белдерде. Әлбәттә, проблемаларның һәм сорауларның яңалары да җиткерелде, һәм бу табигый да. Аңлавыбызча, киләчәктә район җитәкчелеге юллар, ут һәм су кебек мәшәкатьләр белән бергә үтенечләр буенча авыл клубларын ремонтлау, аларны матди тәэмин итү, күлләрне чистарту, парклар булдыру уе белән яшәгән инициативалы кешеләргә ярдәм итү, тарихи биналарны торгызу кебек эшләрне дә күз угында тотарга ниятли. Бу үзе үк инде авыл халкы ихтыяҗының аз булса да яңа баскычка күтәрелүе турында сөйли бит. Кичәге көннән халык белән очрашулар шәһәр микрорайоннарында башланды.

**Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА**

МАНЗАРА

ПРОБЛЕМА БАР

# Гаеп ...җилдә икән бит!

## Ә зыян кешеләргә төшә

**Быел урамда һава температурасы сизелерлек төшкәч, җилләткеч каналларның төзексезлеге аркасында газ колонкалары, индивидуаль казаннар туңу һәм сүнү очраклары булды.**

Мәсәлән, Куйбышев урамының 29нчы йортында яшәүчеләр өчен яңа ел каникуллары бер дә күңелле булып чыкмый. Җилләткеч каналның төзек булмавыннан 15нче фатирда газ колонкасы туңа.

– Йорт яңа санала, аның әле гарантия срогы да чыкмаган, – дип сөйли фатир хуҗасы Ләйлә Вафина. – Әмма җилләткеч канал белән проблемалар элек тә булган, күрәсең. Чөнки элеккеге хуҗалар һава суырту уентыгын томалап куйганнар иде. Моның сәбәбе кире тартудадыр, мөгаен.

Бу фаразны фатирны тикшерүләр дә раслады, анысын 14 гыйнварда махсус комиссия үткәрде. Аның составында шәһәр башкарма комитеты, ТСЖ, "УС һәи ТКХ" МУПы, "Нурлатгаз" җитәкчеләре һәм вәкилләре бар иде. Актта болай язылган: "Тикшерүдән түбәндәгеләр ачыкланды: җилләткеч канал дөрес эшләми һәм сыйфатлы тартуны тәэмин итми. Кире тарту нәтиҗәсендә газ колонкасы туңган..."

Бу йорт үзәкләштерелгән җылытуга тоташкан, ә кайнар су өчен газ колонкалары куелган. Йортта яшәүчеләр әйтүенчә, колонканы кабызган чакта проблема юк сыман үзе, әмма күршеләре белән килеп туган хәл башкаларны да борчуга салган. Чөнки әлеге яшь хатын-кыз үз фатирын да, астагы каттагы күршеләрен дә су басуга китергән хәл - колонканың ник туңу сәбәбен ачыклау өчен төрле службаларның бусагасын таптарга мәҗбүр булган. Шөкер, күршеләре хәлгә керә торган кешеләр әле, басымчыкламыйлар, әмма зыянны барыбер капларга кирәк, әлбәттә.

Шулай да бу йортта газ колонкалары төтен юлларын һәм җилләткеч каналларны тикшерү актлары нигезендә файдалануга тапшырылгач, мондый хәл ничек килеп чыга ала соң? Әлеге актларда барлык фатирларда да тарту җайланмасының барлыгы расланган бит. Бу хәлдән соң ВДПО, җилләткеч каналның төзек булмавы сәбәпле, газ колонкасыннан файдалану тыела, дигән заключение бирә.



**ДМИТРИЙ НИКОЛАЕВИЧ ЛИ-ЧАН-ЖУ**

*Нурлатлы, 4нче мәктәпне, аннан Казан дәүләт техник университетын тәмамлаган.*

*ТР ВДПОсының Нурлат төбәк бүлеген 2014 елның августыннан җитәкли.*

– Йорт җил агымы зонасында тора, күрәсең, – ди ВДПО җитәкчесе Дмитрий Ли-Чан-Жу, җилләткеч каналда кире тартуның төрле сәбәпләрдән килеп чыгу ихтималын ассызыклап. Бүгенге көндә исә шәһәр башкарма комитеты эшне ачыклау һәм чаралар күрү өчен документларны Чистай торак инспекциясенә юллады.

Бу йорт "Уютный дом" ТСЖсына карый. Аның җитәкчесе Минсәгыйть Хәсәнҗанов әйтүенчә, моңа кадәр җилләткеч каналларга хезмәт күрсәтүгә килешүне алар ЦПС белән төзегәннәр икән.

– Килешү төзелде, алар башкарырга тиешле эшләр өчен акча түләнде, – диде ул. – Әмма быелдан безнең баланста булган барлык йортлардагы җилләткеч каналларга хезмәт күрсәтү өчен килешүне ВДПО белән төзибез. Фатир саен йөрибез, кайда каналларны чистартырга кирәк – аларын чистартабыз. Җилләткеч каналларның торышы турындагы актларны фатир хуҗаларының кулларына тоттырабыз. Эшләмәүче җилләткеч каналы белән килеп туган хәл шәһәрдә бердәнбер түгел. Ленинград ур., 13тә әле ике ел элек кенә капиталь ремонт ясаганнар иде. Әмма җилләткеч системага тотынмаганнар. "Бөтен йорт ризасызлык белдергән иде. Килеп карыйлар да китәләр. 2014 елда ясыйбыз, диделәр, әмма бүгенгә кадәр берәү дә килеп басмады. Тарту булмаганлыктан, беренче катлардагы ванналарда стеналар карала", – дип зарландылар телефон аша әлеге йортта яшәүчеләр. Бу йортка хезмәт күрсәтүче "Коммунальник" ТСЖсы рәисе Марат Хәмидуллинның җавабы мондый иде:

– Без җилләткеч каналларга хезмәт күрсәтүгә ВДПО белән килешү төзедек. Бу йортта каналларны февральдә тикшерә башлаячакбыз. Җилләткеч каналда кире тартуны тикшерүдә безнең тәҗрибәбез бар инде. Мисал өчен, Кариев урамындагы 24нче йортта төтен юлындагы 3 рәт кирпечне сүтәргә, кайберсендә, киресенчә, өстәргә туры килде. Ленинград урамындагы әлеге йортта төтен юлы тышланган, аның өстенә козырек та куелган. ВДПО хезмәткәрләре җилләткеч каналларны тикшергәннән соң, бу проблеманы хәл итү юлы табылыр, дип уйлыйм.

– 2 февральдә без килешүләр төзегән ТСЖларның йортларында җилләткеч каналларны тикшерә башладык, – диде ВДПО начальнигы. – Бу исемлектә Ленинград ур., 13тәге йорт беренче булды. Каналлардагы тартуга күп нәрсә йогынты ясый, шул исәптән, тәрәзәләрнең герметиклыгы да. Агач рамлы тәрәзәләрдәге ярыклардан һава керә, ә пластик тәрәзәләр аша ул азрак үтә, бу җилләтү системасының тарту эшен боза. Мисал өчен, тарту белән проблема булган бер фатирда форточканы ачуга ук, вентканалда тарту яхшырды. Әмма тартуның булмавы яки кирегә эшләвенең конкрет сәбәбен ачыклыйсы бар әле. Бәлкем, проект дөрес ясалмагандыр, яки төтен юлларының оголовкалары төзек түгелдер. Вентканалларны яңабаштан ясарга яисә төтен юлларының оголовкаларын күтәрергә туры килүе дә ихтимал.

Күргәнебезчә, җилләткеч каналлар белән проблемалар юк түгел, һәм бу 1-2 йортка гына кагылмый. Торак милекчеләре ширкәтләре, идарәче компанияләр җитәкчеләре бу уңайдан ВДПО ярдәменә исәп тоталар.

**Редакциядән:** Җилләткеч системасы турындагы сүз шуның белән генә ябылмый әле. Без Куйбышев урамындагы проблеманың ничек хәл ителүен күз угында тотачакбыз. Анысын да җил очыртып китмәгәе...

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

ТАБИГАТЬ ҺӘМ БЕЗ




ӘМИР ӘНДӘРҖАНОВ БЕЛӘН ӘНВӘР НАСЫЙБУЛЛИН БӨРКЕТНЕ ВЕТБЕЛГЕЧКӘ АЛЫП КИЛГӘННӘР

# Яралы бөркет яклау тапкан

**Чулпанлы Әмир Әндәрҗанов "Сөләйманов Ә.И" КФХсында электрик булып эшли. Ә бөркетне ул хуҗалыкның сөт комплексында очрата – кошның бер канаты яраланган, бик авырлык белән генә оча, шуңа да азык эзләп кешеләр тирәсенә елышкан.**

- Бөркетне тотарга теләп карадым, тоттырмады, - ди Әмир ага. – Әмма шул көенчә дә калдырырга кызгандым, чөнки кышкы суыкларда, бураннарда юкка чыгачак, төрле урман җанварларының корбаны булуы да бар. Тота алмагач, коштан берничә метр ераклыкка утырдым да, сөйләргә тотындым. "Курыкма, булышам гына, язга тагын китерермен", - дим. Ни гаҗәп, шуннан соң янына килсәм, качмады, канатларын җәеп үзе кочакка кергән кебек булды.

Хәзер бөркет Әмир аганың хуҗалыгында, аның кайгыртуы астында яши. Күбрәк ит, балык ярата икән. Хуҗасына ияләшеп тә килә инде. Һәм Әндәрҗановларны гаҗәпләндерүен дәвам итә.

- Бөркет ау кошы булгач, аудан бөтенләй бизмәсен инде дип, ул торган бинага үземнең хуҗалыктагы йорт куянын кертеп җибәргән идем. Бөркетем куянга тимәде, икәүләшеп яшиләр хәзер, - ди. Күрәсең, игелеккә усаллык белән җавап бирәсе килми бөркетнең дә!

Бу көннәрдә Әмир Әндәрҗанов авылдашы Әнвәр Насыйбуллин белән яраланган бөркетен ветеринария лечебницасына белгечләргә дә алып килгәннәр иде. Кызганычка каршы, канат сынганнан соң шактый вакыт үткән һәм ул дөрес ялганмыйча үскән икән. Канатын сындырып, гипс салырга тәкъдим итсәләр дә, әлегә ризалаша алмый Әмир ага. Ә бөркетне язын, җирләр кардан арына башлагач, янә тоткан урынына җибәрергә җыена. Табигатьтә ул үз-үзен яклый алыр, ә кешеләр тирәсендә һәрчак ризыклы булыр, дип өметләнә ул.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

ЭШМӘКӘРЛЕК

# "Максат" үсешкә йөз тота

**Узган атнада районның кече һәм урта эшмәкәрлек вәкилләре "Максат" пилот проектының попечительлек Советы белән Нурлат районы эшмәкәрлек Советының киңәйтелгән утырышында катнаштылар.**

Нурлатның урта һәм кече эшмәкәрлек вәкилләре белән чираттагы тапкыр Татарстанның урта һәм кече эшмәкәрлек педприятиеләре ассоциациясе вице-президенты Рәфыйкъ Шәйхетдинов очрашты. Бередә 2014 елның икенче яртыеллыгында проектның үтәлеше нәтиҗәләре хакында сөйләштеләр һәм агымдагы чорга планнарны карадылар.

- Быел ешрак очрашырбыз, ахрысы, - диде сөйләшү башында Рәфыйкъ Шәйхетдинов, республика районнарының эшмәкәрлек советлары күзәтчелек органнары, санитар-эпидемиологик, янгын һәм башка службалар белән очрашуларны ешрак үткәрергә планлаштыруларын билгеләп. Бу шул исәптән кече һәм урта эшмәкәрлек вәкилләренә карата таләпләрне кырысландырмауны контрольдә тоту өчен дә эшләнә.

– Башка төбәктәге күршеләр белән мөнәсәбәтләрне җайларга, алар белән партнерлык элемтәләре урнаштырырга, – дип тәкъдим итте ул. Моның мәгълүматларны оператив рәвештә алмашу өчен мөһимлеген билгеләп үтте. Район башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары Руслан Морадыймов районда 1558 урта һәм кече эшмәкәрлек субъекты теркәлүен билгеләп үтте, шуларның 1038е - шәхси эшмәкәр.

- Районда авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә ярдәм итү максатыннан үткәрелгән чаралар нәтиҗәсендә гаилә фермаларының саны арту ягында: 2013тә 28 булса, 2014тә 34кә җиткән, - диде ул. – Гаилә фермаларына ярдәм кысаларында район бюджетыннан 18 гаилә фермасы 5 миллион сум күләмендә максатчан финанслау алган. Шулай ук шәхси ярдәмче хуҗалыкларында 5тән артыграк сыер асраучыларга саву аппаратлары алуга 1 миллион сум бүлеп бирелгән, 7 кеше сөт җитештерүне үстерүгә, терлекчелек фермалары төзүгә 14 миллион сумга якын акча алган.

Утырыш барышында эшмәкәрләрне дә тыңладылар. Районның эшмәкәрләр советы рәисе Халидә Әбделманова бүгенге көндә эшмәкәрлек үсешенә комачаулаучы факторлар турында үз фикерен җиткерде. Бу арендә түләвенең югары булуы, лицензия, кредитлар алуда барьерлар һ.б.лар. Төп мотив буларак районда җитештерү мәйданчыклары булмауны атады ул. Эшмәкәрләр сәяси вакыйгалар белән бәйле рәвештә барлыкка килгән проблемаларын да уртаклаштылар. Бу иң беренче чиратта түмәрләп сатучыларның бәяләрне арттыруына кагыла. Руслан Морадыймов моңа хәзер тикшерүләр бөтен Россия буйлап бара, ә эшне кибетләрдән башладылар, дип җавап бирде. Челтәр кибетләре һәм салымнарга карата да фикер белдерүчеләр булды. Бу уңайдан катнашучылар эшмәкәр Сергей Бархаткинның салым салу буенча тигез булмаган шартлар турындагы фикерен хупладылар.

- Тулаем алганда, эш аз әле, әмма бу беренче адымнар гына бит, аннан башка алга барып булмас иде, - диде Рәфыйкъ Шәйхетдинов, йомгак ясап. – Бездә сезнең районның эшмәкәрлек үсешендә нинди потенциалга ия булуы турында күзаллау туды. Кризис алды күренешләре дә, яхшы якка үзгәрешләр дә бар.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

# БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

**Решение от 25.01.2015 г. о результатах местного референдума 25 января 2015 года на территории Якушкинского сельского поселения Нурлатского муниципального района по вопросу введения и использования средств самообложения граждан размещено на официальном сайте Нурлатского муниципального района в разделе «Якушкинское сельское поселение»**


**Даём заём!** *Реклама*

быстрое решение

- **Под зарплату**
- **Пенсионерам**
- **Под залог недвижимости, автомобиля, ПТС**

г.Нурлат, ул. К.Маркса, 41, ТД "Персона", офис 108.тел.(84345) 2-32-92

ООО "Заем-16"

ООО «Заем-16» свидетельство о внесении сведений в государственный реестр микрофинансовых организаций ФСФР РФ, за №651303392003211 от 21.05.2013 г. ООО «Заем-16» выдает займы при положительном рассмотрении заявки: до 10000 руб. на срок от 7 до 45 дней под 1,5% в день, до 30000 руб. на срок от 1 до 18 месяцев под 9% в месяц из расчета начисления % на остаток суммы ежемесячно, до 300000 руб. на срок от 1 до 18 месяцев под залог автомобиля, под 9% в месяц из расчета начисления % на остаток суммы ежемесячно. За каждый день просрочки пенни 0,1% суммы к оплате. Данное предложение не является публичной офертой.

**Мөгезле эре терлек ите сатып алабыз.**
**Т.: 8-927-430-25-58, 8-937-578-06-57.**

**Ассортиментта КИРПЕЧ, ГАЗОБЕТОН (ТЕПЛОН, УНИБЛОК). Үзегез алып китәсе.**
**Т. 8-937-598-32-75.**

**«ДОМАШНЯЯ КУХНЯ» КАФЕСЫНДА**

*сезнең өчен һәрчак кайнар төшке ашлар, яңа пешкән камыр ризыклары.*

*Юбилейлар, тантаналы, искә алу кичәләре үткәрәбез.*

*Заказга хәләл пилмәннәр, токмач ясыйбыз, салатлар, бавырсак, пироглар, чәк-чәк пешерәбез.*

**Сезне 8.00-18.00 сәг.тә Гыйматдинов ур., 52дә**
*(БТИ бинасы янында)* **күрсәк шат булырбыз.**
**Т. 8-927-443-65-01.**

**7 ФЕВРАЛЬДӘ**
**ЦРБ поликлиникасында**

*ТҮБӘНДӘГЕ ЮНӘЛЕШЛӘР БУЕНЧА КАЗАН ШӘҺӘРЕНЕҢ МДЦ ТАБИБЛАРЫ КАБУЛ ИТӘ:*
***Эндокринология*** *Неврология Кардиология*
***Кан тамырлары хирургиясе*** *(аппаратура белән)*
*Табиблар югары технологияле җиһазлар ярдәмендә тикшерәләр.*

**Т. 8-917-269-54-27.**
КИЛЕШМӘСКӘ МӨМКИН.
БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ КИРӘК

Продажа и установка тахографов с блоком СКЗИ от 38 000 за штуку

Изготовление карт водителей и предприятия для тахографов



Цифровая безопасность

Телефон 8 800 700 54 60
Отдел продаж 8 917 245 07 29
E-mail: sales@dskazan.ru

Реклама

**12 ФЕВРАЛЬДӘ**
**"ДОКТОР ОПТИКА" салонында**
*(Совет ур., 120)*

офтальмология юнәлеше буенча ***академик Св. Федоров исемендәге "Күз микрохирургиясе"*** Чабаксар фәнни-техник үзәге белгечләре кабул итә. *Ерактан начар күрү, якыннан начар күрү, астигматизм, катаракта, глаукома, кылый күзлелек һ.б. күз авырулары проблемаларын хәл итү.*

Алдан язылу **2-17-88, 8-927-427-79-27** тел. буенча.
**КИЛЕШМӘСКӘ МӨМКИН. БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ КИРӘК.**

*РОСМЕДТЕХНОЛОГИЯнең академик С.Н.Федоров исемендәге "Күз микрохирургиясе" тармакара фәнни-техник комплексы" ФДУсы*
Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль служба тарафыннан 30.04.08 елда бирелгән 99–01–005317 лицензия.

**«ДОКТОР ОПТИКА» САЛОНЫ**

**Офтальмология өлкәсендәге белгеч консультация бирә*
**Күзләрне тикшерү, күзлекләр һәм контакт линзалары сайлау*
**Өр-яңа немец җайланмасында барлык төр күзлекләр ясау*
*«Доктор Оптика» - сезнең күзләрегез өчен оптика!*

**Нурлат, Совет ур., 120,**
**тел.: 2-17-88, 8-927-427-79-27;**
**Гыйматдинов ур., 81,**
**тел.: 2-91-99, 8-937-610-69-30;**
**«Шифа» СҮ, Кариев ур., 1Д**
**тел. 8-937-246-56-55.**
**КИЛЕШМӘСКӘ МӨМКИН. БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ КИРӘК.**

Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт тарафыннан 13.12.07 елда бирелгән 16-01-000675 лиц.


**Список избирательного участка местного референдума 22 февраля 2015г. на территории Новоиглайкинского сельского поселения:**
**Новоиглайкинский избирательный участок №2339.**

Границы: с. Новое Иглайкино, д. Старое Иглайкино, д. Светлое Озеро, пос. Тукай, пос. Некрасовка, ж/д разъезд Клиновка.
Местонахождение: с. Новое Иглайкино, Новоиглайкинская средняя школа, ул. Чапаева, д. 22, тел. 3-36-19.
Количество избирателей: 875.


**"САУЛЫК"**
**консультация-диагностика үзәгендә**
*(Нурлат, Жемчужная ур., 25) түбәндәге юнәлешләр буенча*
**Казан шәһәре белгечләре кабул итә:**

Реклама

**7 ФЕВРАЛЬДӘ:**

**1. Гастроэнтерология.**
**2. Онкогинекология-эндокринология, менопауза буенча белгечлек.**
*Табиблар йөрәкне тикшерәләр, ЦДК (төсле доплер картага төшерү) белән эхокардиоскопия ясыйлар.*

**8 ФЕВРАЛЬДӘ:**

**1. Кардиология, ревматология.**
**2. Гинекология.**
**2. Диетология.**
*Табиблар кече оча сөяге органнарын, 1, 2 һәм 3 триместрларда яралгыны тикшерәләр.*

**14 ФЕВРАЛЬДӘ:**

**1. Гастроэнтерология.**
**2. Өлкәннәр, яшүсмерләр гинекологиясе.**
**3. Кардиология, ревматология.**
**4.Невропатология.**
**5. Кан тамырлары хирургиясе.**
*Табиблар йөрәкне тикшерәләр, ЦДК (төсле доплер картага төшерү) белән эхокардиоскопия ясыйлар, баш мие һәм аяк-куллардагы кан тамырларын тикшерәләр.*

**15 ФЕВРАЛЬДӘ:**

**1. Эндокринология.**
**2. Отоларингология.**
**3. Андрология.** Эректиль дисфункция, ЗППП, ирләрдәге нәселсезлек, хр. простатит, мәне бизе аденомасы булганда ярдәм итү.
**4. Аллергология. Иммунология. Бронхиаль астма, аллергияле дерматитлар, тире авырулары проблемаларын хәл итү.**
*Табиблар кече оча сөяге органнарын, 1, 2 һәм 3 триместрларда яралгыны тикшерәләр.*

**КОНСУЛЬТАЦИЯ-ДИАГНОСТИКА ҮЗӘГЕ ВАК КАН ТАМЫРЛАРЫ, АЯКЛАРДАГЫ КАН ТАМЫРЛАРЫ ПӘРӘВЕЗЕ ПРОБЛЕМАЛАРЫН ЧИШҮ ЮЛЛАРЫ ТӘКЪДИМ ИТӘ.**
Тикшерү нәтиҗәләрен БМСЭ кабул итә.

**Белешмәләр һәм алдан язылу өчен т.: 2-43-03, 8-927-037-40-01.**
"Услуга" ОООсы. "Саулык" КДҮсе. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тараф. бирелгән 30.09.2010 елгы ЛО-16-01-001191 лиц. ОГРН 1021605358103.
**КИЛЕШМӘСКӘ МӨМКИН. БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ КИРӘК.**


**СООБЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ ОБЩЕГО СОБРАНИЯ СОБСТВЕННИКОВ ОБЩЕЙ ДОЛЕВОЙ СОБСТВЕННОСТИ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА**

Характеристики земельного участка:
Местонахождение: Республика Татарстан, Нурлатский муниципальный район, х-во ПК А/Ф «Черемшан»
Общая площадь: 27655036 кв. м
Кадастровый номер: 16:32:000000:0234
Целевое назначение (категория): земли сельскохозяйственного назначения.
Уважаемый собственник!

Сообщаем Вам о том, что «13» марта 2015 года в 17:00 состоится общее собрание собственников общей долевой собственности земельного участка.

Собрание проводится в очной форме (присутствие собственников для обсуждения вопросов повестки дня и принятия решений по вопросам, поставленным на голосование),

Место проведения собрания: Республика Татарстан, Нурлатский район, село Якушкино, улица Московская, дом 2А.

Время начала регистрации собственников: 16 часов 00 минут местного времени.

Время окончания регистрации собственников: 16 часов 50 минут местного времени.

ПОВЕСТКА ДНЯ:

1. О выборах председателя и секретаря собрания.
2. Об утверждении списка участников общей долевой собственности.
3. Об избрании лица, уполномоченного представлять участников общей долевой собственности при их взаимоотношениях с органами исполнительной власти Республики Татарстан, местной администрацией, ООО Торговый дом «Агромир».
4. О месте хранения списка участников общей долевой собственности и протоколов общих собраний, выборе лица, ответственного за их хранение.
5. О передаче земельных участков общей долевой собственности в аренду ООО Торговый Дом «Агромир».
6. Об утверждении величины арендной платы, а также формы оплаты арендной платы по договорам аренды с ООО Торговый дом «Агромир».

С информацией и (или) материалами, которые будут представлены на общем собрании, можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, Нурлатский район, село Якушкино, улица Школьная, дом 6, - с 14:00 до 17:00.

Вы вправе участвовать на общем собрании как лично, так и через своего представителя. Для личного участия Вам необходимо иметь при себе паспорт и документ, подтверждающий право собственности. Полномочия представителя должны быть подтверждены доверенностью, оформленной в порядке, предусмотренном действующим законодательством.

**С уважением, Х.Х Хамидуллин**

**СООБЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ ОБЩЕГО СОБРАНИЯ СОБСТВЕННИКОВ ОБЩЕЙ ДОЛЕВОЙ СОБСТВЕННОСТИ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА**

Характеристики земельного участка:
Местонахождение: Республика Татарстан, Нурлатский муниципальный район, Егоркинское сельское поселение;
Общая площадь: 38410960 кв. м;
Кадастровый номер: 16:32:000000:207;
Целевое назначение (категория): земли сельскохозяйственного назначения.
Уважаемый собственник!

Сообщаем Вам о том, что «13» марта 2015 года в 14:00 состоится общее собрание собственников общей долевой собственности земельного участка.

Собрание проводится в очной форме (присутствие собственников для обсуждения вопросов повестки дня и принятия решений по вопросам, поставленным на голосование),

Место проведения собрания: Республика Татарстан, Нурлатский район, село Егоркино, улица Центральная, дом 33.

Время начала регистрации собственников: 13 часов 00 минут местного времени.

Время окончания регистрации собственников: 13 часов 50 минут местного времени.

ПОВЕСТКА ДНЯ:

7. О выборах председателя и секретаря собрания.
8. Об утверждении списка участников общей долевой собственности.
9. Об избрании лица, уполномоченного представлять участников общей долевой собственности при их взаимоотношениях с органами исполнительной власти Республики Татарстан, местной администрацией, ООО Торговый дом «Агромир», ООО «Агро-Развитие».
10. О месте хранения списка участников общей долевой собственности и протоколов общих собраний, выборе лица, ответственного за их хранение.
11. О расторжении договора аренды с ООО «Агро-Развитие» и передаче земельных участков общей долевой собственности в аренду ООО Торговый Дом «Агромир».
12. Об утверждении величины арендной платы, а также формы оплаты арендной платы по договорам аренды с ООО Торговый дом «Агромир».

С информацией и (или) материалами, которые будут представлены на общем собрании, можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, Нурлатский район, село Егоркино, улица Центральная, дом 33, - с 14:00 до 17:00.

Вы вправе участвовать на общем собрании как лично, так и через своего представителя. Для личного участия Вам необходимо иметь при себе паспорт и документ, подтверждающий право собственности. Полномочия представителя должны быть подтверждены доверенностью, оформленной в порядке, предусмотренном действующим законодательством.

**С уважением, В.С. Яковлева**

**УВАЖАЕМЫЕ ЖИТЕЛИ РЕСПУБЛИКИ!**

ОАО «Сетевая компания» информирует вас о мерах предосторожности при эксплуатации электрооборудования и электроотопительных приборов в период низких температур для недопущения перегруженности электрических сетей и пожаров.

**Для того, чтобы при использовании электрооборудования, электроотопительных и электронагревательных приборов не возникло ситуаций, способствующих перегрузке электрических сетей и возникновению пожаров, необходимо помнить:**

- без необходимости не включайте одновременно в сеть все имеющиеся в доме электроприборы, а если вы уходите из дома, выключайте их из сети. Одновременное включение в электросеть нескольких электроприборов большой мощности ведет к ее перегрузке и может стать причиной пожара;
- ни в коем случае нельзя пользоваться поврежденными розетками и выключателями. Если при включении или выключении бытовой техники в розетку вы видите искры, если розетки нагреваются при включении в сеть бытовой техники – это признак слабых контактов. Лучший способ предотвратить скорый пожар – заменить розетку. Помните, что предохранители и автоматы защищают от коротких замыканий, но не от пожара из-за плохих контактов;
- не используйте в быту дешевых розеток и удлинителей. Не пользуйтесь розетками, рубильниками, другими электроустановочными изделиями с повреждениями. Они многократно увеличивают риск пожара. Не экономьте на своей безопасности, покупайте только сертифицированную электрофурнитуру;
- ремонт неисправных электробытовых приборов должен производиться только квалифицированными специалистами. Особую опасность представляют собой приборы с пересохшими или поврежденными проводами, с видимым нарушением изоляции;
- не допускайте использования горючих абажуров на электролампах;
- не допускайте устройства временных самодельных электросетей в помещениях. Замените оголенные и ветхие электрические провода;
- соединение электрических проводов следует производить путем пропайки или опрессовки;
- исключите попадание шнуров питания электрических обогревателей в зону теплового излучения и воду;
- соприкосновение обогревателей и отопительных приборов с мебелью и тканями вызывает тепловое воспламенение, поэтому при их эксплуатации рекомендуется использовать несгораемые токонепроводящие подставки;
- не допускайте эксплуатации самодельных электроотопительных и электронагревательных приборов;
- не допускайте включения электронагревательных приборов без соединительной вилки;
- нельзя пользоваться электронагревательными приборами, не имеющими устройств тепловой защиты, а также при отсутствии или неисправности терморегуляторов, предусмотренных конструкцией;
- не оставляйте без присмотра включенными в электрическую сеть электронагревательные приборы, а также другие бытовые электроприборы, в том числе находящиеся в режиме ожидания, за исключением электроприборов, которые могут и (или) должны находиться в круглосуточном режиме работы в соответствии с инструкцией завода-изготовителя;
- если при включении того или иного электробытового прибора освещение мерцает или становится чуть темнее, это верный признак того, что внутридомовая электрическая сеть перегружена. В большинстве случаев проблема кроется в небрежных скрутках и соединениях электрических проводов или слабо затянутых контактах. Все это может стать причиной пожара. В данном случае нужно срочно вызывать квалифицированного электромонтера.

Выполнение этих несложных правил обезопасит вас от пожаров, а электрические сети от перегрузок. Берегите себя! Будьте здоровы!

*На правах рекламы*


**Гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" ААҖ** **www.tatmedia.ru** **www.nurlat-tat.ru** **Реклама хезмәте телефоны:** 8 (84345) 2-36-12

"Дуслык" ("Дружба", "Туслах") газетасы
Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

"Татмедиа" ААҖ филиалы директоры – баш мөхәррир С.Н. Хәйруллина
Тел.: 2-36-14

**Редакциянең адресы:**
423040, ТР, Нурлат шәһәре, К.Маркс ур., 19
**Электрон адрес:** e-mail: redak@list.ru
**Телефоннар**: 2-36-12 – җаваплы сәркатип, реклама бүлеге, факс
2-36-20 – рус бүлеге
2-36-13 - корреспондентлар
2-25-88 – бухгалтерия

**Нәшер итүче:**
"ТАТМЕДИА" ААҖ
420097, Казан шәһәре, Академическая ур., 2

Газета элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы (Татарстан) идарәсе тарафыннан 2013 елның 16 маенда теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы: ПИ № ТУ 16-01018
Бу сан "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел – Пресс" полиграфия-нәшрият комплексы" ААҖндә басылды
Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2.
Басуга тапшыру вакыты:
график буенча – 14.30,
фактта – 14.30

татмедиа

Тираж сертификатлаштырылган
Тираж - 2041

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда яклаучы булып чыгарга мөмкинлеге юк.
**Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**
Реклама белдерүләренең төгәллеге өчен реклама бирүче үзе җаваплы.

Газета **чәршәмбе** һәм **җомга** чыга.
Заказ-наряд №5916
Язылу индексы – 16185
Бәясе ирекле.

16+


© Язмаларны күчереп бастыру редакциянең язмача рөхсәте белән генә мөмкин.

ХӘТЕР. ХАТИРӘ

## “Кадерле кунак булдым”

**Нурлатта яшәүче Таһир Каняфин Гыйматдиновлар гаиләсенә кагылышлы гади генә бер вакыйга гомерлеккә хәтергә сеңеп калды, ди.**

*– 1978-79 еллар иде ул. Мин яңарак кына армиядән кайтып, Фома авыл Советында бухгалтер булып эшләп йөри идем. Бервакыт шулай ук легендар шәхес, җирле “Игенче” колхозының данлыклы рәисе Сәлим ага Гафуров белән район сессиясенә бардык. Утырыштан соң, эшләрне бетергәч, Сәлим Салихович мине дә ияртеп Габбас Кыямовичларга киттек. Әлбәттә, районның иң зур җитәкчесе өенә керергә батырчылык итмәдем, Сәлим абыйга әйттем дә, урамда калдым. Бераздан Габбас Кыямовичның җәмәгате Надия апа чыкты да: “Энем, бездә капка төбендә тору гадәте юк”, – дип, мине җилтерәтеп өйгә алып керде, ике зур җитәкче янына табынга утыртты. Шул чакта Габбас Кыямовичның гадилегенә чын-чынлап шаккаттым мин, сокландым да: ул минем хәлләрне сорашты, эш-планнарым белән кызыксынды. Шулай да, бераз тамак ялгап алгач, сезнең сөйләшер сүзләрегез бардыр, мин чыгып машинаны карый торам әле, диеп, табын янынннан кузгалдым. Соңрак билгеле булганча, Габбас аганың күңеленә минем болай эшләвем дә бик хуш килгән икән. Сәлим ага да чыккач аталарча, аркамнан кагып: “Молодец. энем, Габбас Кыямович мактады үзеңне, бу егет булдыклы күренә, бик яхшы кадрың бар икән, дип әйтте”, – дип тә үсендереп җибәргәч, түбәләр күккә тиде инде. Әмма иң мөһиме: безнең өчен буй җитмәстәй тоелган шәхес Габбас Кыямовичның, аның җәмәгате Надия апаның кече күңелле, кунакчыл һәм гап-гади кешеләр булуына, район хуҗасының гап-гади авыл малае белән бер табында утыруны түбәнчелеккә санамавына гаҗәпләндем дә, сокландым да.*

## “Бөгелмәгә китмәдем...”

**Ислам Бәхтияров, халык мәгарифе отличнигы, Нурлат шәһәренең Мактаулы гражданины:**

*– Үземнең 1нче мәктәп директоры булып китү вакыйгасын искә төшереп үтәсем килә. 1977 елда Геленджикта ял итәргә туры килде. Анда сыйныфташым, Кизләү егете Гариф Закиров та ял итә икән. Гариф ул чакта Бөгелмә шәһәрендәге мәктәпләрнең берсендә директор булып эшли иде. Шулчак мине дә котыртты бит бу: шәһәргә күчәсең килсә, әйдә, безгә, 11нче мәктәпкә директор кирәк, РОНО мөдире белән сөйләшәм, ди. Дөресен әйтим, кызыктырды Гариф мине. Ялдан соң туп-туры Бөгелмәгә кайтып та төштем. РОНО мөдиренә ризалык бирдем, мәктәпне дә карап чыктык. Әмма минем ризалык кына җитми, үзебезнең райком сүзе дә кирәк бит әле дип, Нурлатка кайттым. Икенче көнне иртүк райкомга киттем, икенче секретарь минем нинди йомыш белән йөрүемне бер дә ошатмады. Габбас Кыямович бөтенләй сүгеп ташлар инде хәзер дип, курка-курка гына аңа кердем. Ә ул һич тә күтәреләп бәрелмәде: әйдә, утыр әле, ипләп кенә барысын да сөйлә, аннан карарбыз, диде. Үзем сөйлим, үзем кайчан туктатыр да, куып чыгарыр икән, дим. Ә Габбас Кыямович куарга ашыкмады: яхшылап уйла әле, ике көннән соң килерсең, ди. Аның икенче килүемдә әйткән сүзләренең никадәр гыйбрәтле, тормышчан булуына еллар узган саен ныграк инана бардым. Бу киңәш-нәсыйхәтләрне беркайчан да онытасым юк:*

*– Ислам, менә синең барлык туганнарың, дусларың да монда. Дөрес, Гариф яхшы кеше, бергә эшләгән дә идек, әмма чит, зур шәһәрдә ул гына җитмәячәк бит. Менә мин дә Чирмешәннән, барлык туганнарым анда, якын булса да, әлләни еш кайтып булмый – әнә шул ягын әйбәтләп уйладыңмы? Шәһәргә күчәргә телисең икән, 1нче мәктәпкә директор итеп куябыз сине, тәҗрибәң бар, эшләрсең, – диде ул. Шулай итеп, җәмәгатем белән киңәштек тә, бу тәкъдимгә ризалаштым мин һәм гомерем буена бер генә дә үкенгәнем булмады. Үз гомеремдә байтак җитәкчеләр белән эшләргә туры килде, әмма Габбас Кыямович кадәр һәр кешене үзенә тиңгә күреп исәпләшүчеләре, кадрларның кадерен белүчеләре, кул астындагыларга ни кирәклеген аларның үзләреннән дә сизгеррәк тоючылары булмагандыр, мөгаен.*

**Илназ МӨБАРӘКШИН** язып алды

ҖИҢҮНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

## Алар тәмуг газабын узган...

**- Быел 27 гыйнварда кем белән очрашачакбыз? – күптән түгел өлкән сыйныфлардан бер укучым әнә шундый сорау бирде. Ул, гимназиядә укучы башка балалар кебек үк, бу көнне традиция буларак безгә кунакка Бөек Ватан сугышының иң кырыс һәм иң коточкыч Ленинград камалышы вакыйгаларын һәм Освенцим лагере газапларын күргәннәрнең килүен яхшы белә.**

Быел исә актлар залында укучылар Ленинград камалышын кичкән Роза Александровна Никматуллова һәм Игорь Петрович Ивлевның хатирәләрен тыңладылар. 7 ел рәттән безгә очрашуга Освенцим концлагеренда булган Раиса Александровна Инякина килә торган иде. Кызганычка каршы, ул узган елның җәендә вафат булды һәм балалар аның белән бергә бу газапны кичкән миллионлаган кешеләрне бер минутлык тынлык белән искә алдылар.

Залда гадәти дәрестә бик сирәк була торган тынлык. Балалар, сулыш алырга да куркып, язмыш кушуы буенча шәһәребезгә күченеп килгән ленинградлыларны тыңлыйлар. Аларның һәркайсының тормышы – халыкка һәм Ватанга тугры хезмәт итү үрнәге.

Видеофильм кадрлары, презентациядән фоторәсемнәр, өлкәннәрнең башларыннан кичкәннәр турында күз яшьләре белән сөйләүләре берәүне дә битараф калдырмады. 7–8 сыйныф укучылары белән бергә залга 11нче сыйныфтан чыгарылышлар да әлеге кыю кешеләрне тагы бер кат күреп, хатирәләрен тыңлап калыр өчен килгән.

Игорь Петровичның бертуган энесе ачлыктан үлә, ул эшкә барганда урамда егылып, госпитальгә эләккән энисен дә югалта. Ә үзен, ач һәм авыру көенчә, балалар йортына, соңрак һөнәр училищесына җибәрәләр, аннан соң ул Совет Армиясендә хезмәт итә... Әнисе белән исә бары 1959нчы елда Ленинградка баргач кына очраша. Ул хәтерендә сакланган урамнар буйлап йөри, кешеләрдән сораша торгач туганнарын һәм иң якын кешесе – әнисен эзләп таба. Игорь Петрович кыенсынып күз яшьләрен сөртә, әмма балалар аның дулкынлануын һәм балачагын искә төшергәндә кичергән йөрәк әрнүен яхшы аңладылар. Ә бит аның балачагы 7 яшендә үк тәмамлана.

Игорь Петровичны гимназия укучылары беренче тапкыр гына күрә әле, ә менә Роза Александровнаны алар күптәнге танышлары итеп каршы алдылар. Күпләр ул китапханәгә бүләк иткән дистәләгән китапларны да укыйлар. Аның оптимистлыгы, энергиясе үзеннән-үзе балаларга күчә.

Кечкенә Роза 1нче сыйныфка баруны зарыгып көтә. Әмма аңа укырга насыйп булмый. Камалыштагы Ленинград, әнисенең үлеме, ятимлек аның хыялларын җимерә. Шуңа да, мөгаен, ул гомере буена китапларга һәм белемгә тартылып яши. Ул тирә-якта барган бар нәрсә белән кызыксына, һәм өлкән яшьтә булуына карамастан, шат күңелле һәм игелекле булуы белән шаккаттыра.

Очрашу тәмамлаганнан соң да укучылар залдан китми тордылар, сораулар яудырдылар, кунакларга очрашуга килүләре өчен рәхмәт белдерделәр һәм истәлеккә фотога төштеләр...

Сугыш елларының тере шаһитлары белән очрашуларның кадерен беләләр алар, чөнки аларның һәркайсы соңгысы булырга мөмкин икәнлеген аңлыйлар. Балалар Ленинград камалышын кичергән Минзиннәт Сәмигулла кызы Бәшированың очрашуыбыз алдыннан гына, 26 гыйнварда вафат булу хәбәрен дә зур әрнү белән кабул иттеләр... Урыны җәннәттә булсын...

**Дания СИБГАТОВА,**
Нурлат

КОНКУРСКА

## “Шатлык” йортында балалар хуҗа

“Май чүлмәге тышыннан билгеле”, - дигән әйтемнең төбендә тирән мәгънә ятканын һәркем беләдер, билгеле. Оныгым Камилне алып чыгыйм дип, “Шатлык” балалар бакчасының капкасыннан узуга, шушы әйтем күңелемнән узды. Биредә чын мәгънәсендә кышның бар матурлыгы, яме, бизәге һәм төп байлыгы булган кардан ясалган “Кышкы фантазия” каршы ала. Кыш Бабай һәм Кар Кызыннан башлап, яңа елның символы булган кәҗә белән сарык, төрле әкият батырлары белән аралаштырылган урман җәнлекләре, йорт хайваннары дисеңме, хәтта төрле буяулар белән буялып, боз белән ялтыратып катырылган елан белән зур яшел бакага кадәр бар. Бакчада эшләүче тәрбиячеләрнең хозурланып сокланырлык “Кышкы фантазияләре” беренче карашка гына матур күргәзмә залын хәтерләтә. Җентекләп карый башлагач, бу фантазиянең карап тору өчен генә түгел, ә бәлки, шушы кар патшалыгында рәхәтләнеп уйнар өчен ясалганлыгын аңлыйсың. Мин моны бер юлы ике “куян ату” дияр идем. Беренчедән, балалар тәрбиячеләре ярдәмендә күпмедер дәрәҗәдә шул матурлыкны ясарга өйрәнә, икенчедән, алар үзләрен чынлап торып шушы патшалыкның нәни хуҗалары итеп тоеп, үз сәламәтлекләрен ныгыталар.


МЕНӘ АЛАР, БАКЧАНЫҢ ЯШЬ ХУҖАЛАРЫ!

**Фәүзия МӨХӘММӘТОВА,**
Югары Нурлат


“ДУСЛЫК” МАЙЯ ПИРАМИДАЛАРЫ ИТӘГЕНДӘ

РАЙОНКА СӘЯХӘТТӘ

## “Дуслык” – Майя пирамидаларында

**Район газетасының дөнья буйлап сәяхәте дәвам итә. Күптән түгел “Дуслык” Америка, Мексикага, Багам утрауларына кадәр барып җитте.**

Нурлатта яшәүче Рәшит һәм Әлфия Гыйльмановлар узган ел азагында Американың Флорида штатындагы Орландо шәһәренә кызлары Зөлфия янына кунакка барганда, үзләре белән “Дуслык”ның да берничә санын алырга булалар.

– Газетаны 50 еллап укыйбыз инде, – дип сөйли Рәшит абый. – Нинди язмалар аеруча ошый, дип сорамасагыз да була – без газетаның бер хәрефен дә калдырмый укып барабыз. Узган ел газетабыз төрле конкурсларда призлы урыннар яулап торды: бу хактагы хәбәрләрне бик сөенеп, үзебезнең уңыш кебек кабул итәбез, горурланабыз. “Дуслык”ның төрле илләргә сәяхәтләре турында да укып тордык. Менә үзебез дә яраткан районкабызны океан аръягына алып чыгарга булдык.

Шул рәвешле, Гыйльмановлар белән бергәләп “Дуслык” Мексикада булып, мәшһүр Майя пирамидаларын да күргән, Багам утрауларында да сәяхәт иткән. Хәтта Нью-Йоркта да Нурлат районы газетасы бар хәзер. Анда тагы бер районташыбыз – Зәйнәп апа Хәйретдинова яши, ул картлык көнендә кызы янына күченеп киткән. Бераз булса да сагынуымны басармын дип, “Дуслык”ның берничә санын үзенә алып калган Зәйнәп апа.

**Илназ МӨБАРӘКШИН**

ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЛАРЫНДА

# Почтачылар нәтиҗәләр ясады

**"Почтальоннарның ике проблемасы бар, шуларның берсе – альтернатив әбунә". Моны коллективның йомгаклау җыелышында Нурлат районара почтамты начальнигы Рәфис Ногманов әйтте. Җыелышта район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Руслан Морадыймов та катнашты.**

Рәфис Ногманов чыгышыннан аңлашылганча, почтачылар эшенең күрсәткечендә хәзер сизелерлек рольне төрле товарлар сату, коммуналь хезмәтләргә түләтүләр уйный. Керемнәр буенча план арттырып үтәлгән. Тулаем алганда, коллектив эшли, төрле басмаларга язылу планы 124 процентка үтәлгән. Ә Совет ур., 24тәге "Нурлат-2" бүлегендә әбунә планын 202 процентка башкарганнар. Тик менә бу саннар залда утыручыларның кәефен әлләни күтәрмәде, һәм канәгатьсез сораулар хезмәт хакына бәйле иде. Бу аңлашыла да, тармак буенча уртача хезмәт хакы 12 мең сум чамасы гына, бу район буенча уртачага якын да килми (2013 елгы мәгълүматлар буенча, 23 мең сум). Бренд – тармак монополисты өчен бик тә тыйнак күрсәткеч бу.

Хәер, хезмәт хакы темасын да, почта хезмәтләренең сыйфатын яхшырту, вакытлы матбугатны үзвакытында китерү кебек мәсьәләләрне дә артык күпертеп тормадылар. Ә бит нәкъ менә соңгысы аркасында күпләр альтернатив язылуны сайлый да.

Бүлекчә начальниклары һәм почтальоннар алдында профком, әбунә һәм икътисад бүлекләре вәкилләре дә чыгыш ясады. Почтачылар район тормышында актив катнаша. Эре почта элемтәсе бүлекчәләре арасында иң уңышлы эшләүчеләрдән дип Мамык, Киекле һәм Тимерлек бүлекчәләре коллективлары аталды, кечеләр арасында иң яхшылары Урта Камышлы, Кизләү һәм Андреевканыкы иде. Бу исә почтальоннарның күп дистә еллар дәвамында формалашкан һөнәри корпусы бар дигәнне раслый. Димәк, аларның хезмәте лаеклы бәяләнергә дә тиеш.

**Валентина ВАФИНА**

СӘХНӘ

# Театрда – премьера

**Бикүле мәдәният йорты каршында эшләп килүче татар халык театры берникадәр елдан соң нурлатлыларга күренекле драматург Наил Гаетбаевның "Әстәгъфирулла" комедиясен тәкъдим итте. Үзешчән артистлар репетицияләрне көздән үк алып барганнар һәм 31 гыйнвар көнне комедияне тамашачылар хөкеменә тапшырдылар.**

– Премьерабыз бик уңышлы булды, халык бик яратып кабул итте. Әлеге комедиянең сюжеты кызыклы да, гыйбрәтле дә, тамашачылар аннан үзләре өчен бик күп рухи азык алганнардыр дип уйлыйм, - дип тәэсирләре белән уртаклашты режиссер Илшат Гайсин.

Төп рольләрне үзешчән артистлар – Бикүледән Тәнзилә Әһлетдинова, Минсабир Мостафин, Миләүшә Заһирова, Нәфисә Хәсәнова, Чулпаннан Кадрия Әндәрҗанова һәм режиссер Илшат Гайсин үзе башкаралар. Ә спектакльне якын көннәрдә районның башка авыллары халкы да тамаша кыла алачак. 4 февральдә Бикүле халык театры Биккол, 5 февральдә Чулпан, 6сында Фома авыллары мәдәният йортларында чыгыш ясарга ниятли.

Нурлат татар халык театры да тамашачыларга бүләк әзерли. Алар Җиңүнең 70 еллыгына Аяз Гыйләҗев повесте буенча әзерләнгән "Яра" спектаклен сәхнәләштерәләр.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

# Яшь "йолдызчыклар" кабына

**Узган җомга көнне Знче мәктәп районның яшь талантларын кабул итте. Биредә "Музыкаль фейерверк" фестиваль-конкурсы үтте.**

Шәһәр һәм авыл мәктәпләренең 1-4 сыйныф укучылары "Соло башкаруы", "Хореографик постановка" һәм "Ансамбль башкаруы" номинацияләрендә 35 чыгыш тәкъдим иттеләр.

– Без районда сәләтле балаларның бик күп булуына тагы бер кат инандык, – ди жюри әгъзаларының берсе, "Чыршыкай" балалар бакчасының музыка җитәкчесе Лилия Маматова. – Һәр балага иҗади сәләтен күрсәтер мөмкинлек бирергә кирәк дип саныйм мин, ә "Музыкаль фейерверк" аларга алга таба үсеш өчен стимул булды.

Балалар сәнгать мәктәбе укытучысы, шулай ук жюри составында булган Ольга Гришина, конкурсны оештыручылар – барлык ваклыкларына кадәр уйлап эш иткән Зnче мәктәп педагогларына комплиментларын җиткерде. Ул да коллегаларының мондый очрашулар традицион булырга һәм елына бер тапкырдан күбрәк уздырылырга тиеш, дигән фикерен хуплады.

– Бу авыллардагы сәләтле балаларга үсү мөмкинлеге бирәчәк. Ни дисәң дә, шәһәрнекеләргә бу уңайдан җиңелрәк бит, – дип билгеләп үтте Ольга Владимировна.

**Маргарита ЛИТТА**

## КОТЛЫЙБЫЗ!

**Иске Әмзә** авылында яшәүче кадерле кодагыебыз **Люция Идрис кызы Нәбиуллинаны** чын күңелдән юбилее белән котлыйбыз! Балаларыбыз кушылган көннән бирле олы гаилә кебек киңәшләшеп яшибез, бердәм булып эшлибез, оныклар үстерәбез, шуңа шөкерана итәбез. Кодагыебызның уңганлыгына, сабырлыгына чик-чама юк, тормышлары бөтен, дөньялары түгәрәк. Кода белән тигезлектә, исәнлектә гомер итсеннәр, калган гомерләребезне дә балалар хөрмәтен тоеп, алар бәхетенә куанып яшәргә язсын!

**Кодалары Минаповлар гаиләсе.**

Кадерле тормыш иптәшем, сөекле әниебез **Люция Идрис кызы Нәбиуллинаны** 60 яшьлек юбилее белән тәбрик итәбез.

Колбай Мораса авылында туып үскән әниебез менә инде 32 ел Иске Әмзәдә ишле, бердәм Нәбиуллиннарның төп йортында килен. Сабыр, киң холыклы, туган җанлы әниебезне бүген тулы бер нәсел токтасы дип атап була. Өч дистә ел дәвамында әмзәлеләргә медицина хезмәте күрсәтте ул, намуслы эшләве нәтиҗәсендә авылдашлары арасында абруе зур аның. Без, 4 кызын яшьли хезмәткә күндереп, тәртипле-тәрбияле итеп үстерүдә дә әниебезнең роле зур булды. Бүген ул 4 оныгының яраткан дәү әнисе.

Кадерле әниебез! Гомер бәйрәмең – юбилееңң белән сине. Сау-сәламәт бул, әтиебез белән озак еллар безнең шатлыкларга сөенеп, күпсанлы туганнарыбызга терәк булып, бәхетле гомер кичерегез.

**Сине яратып тормыш иптәшең Ирек, кызларың, киявләрең һәм оныкларың.**

Кадерле туганыбыз **Гашыйкә Нәбиулла кызы Фатучеваны** 80 яшьлек юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз, исәнлек-саулык, озын гомер телибез.

Карлар ява, карлар ява
Синең туган көнеңдә,
Бәхет, шатлык, озын гомер
Бирсен Ходай үзеңә.

**Мифтаховлар гаиләсе исеменнән сеңлең Нурия.**

## КҮЧЕМСЕЗ МИЛЕК

*Җиңү ур.да йорт. Т. 8-927-405-51-82.

*Төрнәстә 2 бүлмәле фатир. Т. 8-927-405-45-03.

*Җир участогы (корылмалар юк), Алга ур. (Кормыш пос.), ут, газ, су үткәрелгән. Юлга асфальт салынган. Т. 8-927-671-15-60. 1 600/301/14-620462 м/х.

*Йорт. Т. 8-919-684-40-03.

*Үзәктә 2 бүлмәле фатир. Т. 8-927-418-86-92.

*Нигез салынган участок (Түбән Нурлат). Т. 8-927-415-01-51. №16-16-35/017/2011-525 м/х.

*Ашыгыч, Завод ур.да 1 бүлмәле фатир, балкон, пластик тәрәзәләр, төп коммуникацияләр – җылылык һәм канализация торбалары алыштырылган. Асфальтланган ишегалды, йорт сайдинг белән тышланган, фатир 2 катлы йортның 1нче катында. Т. 8-960-056-55-66.

*Завод һәм Дружба ур.да 3 бүлмәле фатирлар. Т. 8-937-283-18-83.

*2 бүлмәле фатир + гараж (базар янында). Т. 8-917-280-66-30.

*Халиков ур.да йорт, 115 кв.м. Т. 8-965-611-15-35.

*Шәһәр үзәгендә (азык-төлек базары янында) гараж. Т. 8-927-442-67-16, Альберт.

*Ашыгыч, бүлмә. Т. 8-927-047-10-21.

*Кирпеч йорт (җиһазлары белән бергә), 100 кв.м, 16 сутый җир, 9х3,5ле мунча (юкәдән, газ белән җылытыла), үзәкләштерелгән канализация, 16х4,5ле гараж, Мифтахов ур., 9-2, 3700000 сум, ашыгыч. Сатулашу. Т. 8-927-671-15-60.

*Йорт, Совет ур., 2А. Т. 8-937-77-40-132.

*Самаренкин ур.да (1нче йорт ишегалдында) гараж, бөтен документлары бар. Т. 8-927-442-24-98.

*2 бүлмәле фатир, 52 кв.м, җиһаз, 1нче кат, лоджия, Садовая ур., 1В-18.

Т.: 8-927-242-24-23, 8-917-889-04-27.

## АВТОТРАНСПОРТ

*«Лада Калина», седан, 2010 елгы. Т. 8-937-524-88-48.

*«Лада Гранта», 2014 елгы. Т. 8-927-038-12-40.

*«Грейт Вал Вингель-5», 2012 елгы, пикап, 470000 сум. Т. 8-927-671-15-60.

*«Дэу Нексия», 2007 елгы, 16-кл., яхшы хәлдә. Т. 8-927-044-72-78.

## БАШКАЛАР

*ПГС, ком, елга ташы, жом. Т.: 8-927-402-13-40.

*Просечкадан коймалар, чардуганнар. Т. 8-917-863-93-44.

*Бодай, арпа. Китерү – түләүсез. Т. 8-937-776-33-35.

***Жалюзи, барлык төрләр. Тиз. Т. 8-927-672-01-17.**

*Кәрәз (Ульяннныкы), 420 сум/кг. Т. 8-927-751-61-46.

*Утын. Т. 8-937-003-27-27.

*Бала караваты, 2 камералы суыткыч. Т. 8-927-031-23-28.

*Үрдәкләр, казлар, эч-башлары. Т. 8-927-244-92-89.

*Утын. Т. 8-987-413-91-33.

*Төсле телевизор, кыйммәт түгел. Т. 8-937-577-65-06.

*Яшь үгез бозаулар. Китереп бирәбез. Т. 8-927-870-49-62.

*Чәчәк балы, 900 сум. Китерәбез. Т. 8-927-440-52-84.

*Автокәнәфи (0-13 кг). Т. 8-929-721-86-01.

*1 яшьлек тана. Т. 8-927-419-89-28.

*ПГС, ком, керамзит, вак таш, елга ташы, кирпеч. Т. 8-927-401-51-91.

*Бала ашату өчен урындык, чана-арба, кулланылган. Т.: 2-44-02, 8-927-247-91-27 (кичке 5тән соң).

*Газ плитәсе (50х50ле), кулланылган, кыйммәт түгел. Т. 8-927-404-39-36.

*Костер, люцерна орлыклары. Т. 8-927-470-39-02.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

***Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.**

***Йомшак җиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.**

*Юрист хезмәтләре. Т. 8-927-415-01-51.

*Сантехника (су, канализация, җылылык үткәрү). Т. 8-927-413-17-69.

*Юрист хезмәтләре: ДТПның иминият түләвен алу. Т. 8-927-415-01-51.

*Йөк күчерү. Т. 8-929-721-37-65.

*Бәхетле туйлар, күңелле юбилейлар. Алып баручылар. 8-950-321-17-29.

*«ГАЗель», йөк күчерү. Т. 8-927-486-10-22.

*Пластик тәрәзәләр ремонтлау. Т. 8-927-249-54-24.

*ПГС, ком, «МТЗ» төягече белән кар чистарту. Т. 8-927-424-02-83.

*Суыткычлар төзәтәм. Т. 8-927-247-93-50.

*Кар көрибез. Т. 8-927-244-84-71.

*Электрик хезмәтләре. Т. 8-987-418-35-00.

*Коелар казыйбыз, чистартабыз. Т. 8-927-481-51-72.

*Сантехника (су, канализация, җылылык). Т. 8-937-526-56-86.

***Йөк күчерү, «ГАЗель», 4 метрлы, тентланмаган. Т. 8-927-401-97-48.**

*Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-927-401-97-48.

*«КамАЗ», 15 т, ком, ПГС. Т. 8-927-454-61-01.

*Нурлат-Самара, өегездән килеп алабаз, 5.00дә кузгалабыз. Т. 8-927-673-79-46.

*Йөк күчерү, «ГАЗель». Т.: 8-987-006-28-73, 8-937-775-97-51.

*Компьютерыгызга ярдәм. Т. 8-909-308-22-56.

*Суыткычлар төзәтәм. Т.: 8-937-610-58-78, 2-71-69.

## САТЫП АЛАМ

***Алгы приводлы «ВАЗ»лар, чит ил машиналары. Кыйммәткә. Т. 8-927-456-00-07.**

*Мөгезле эре терлек ите. Т.: 8-937-008-53-72, 8-927-430-25-58.

## КИРӘК

*Мөгезле эре терлек тиреләре, кыйммәткә. Т. 8-937-281-75-63.

*Мөгезле эре терлек, кыйммәткә. Т. 8-927-412-29-99.

*Оешмага җитәкче өчен фатир. Т.: 2-60-75, 8-9172-67-94-83.

*Чәчтараш, 60%. Т. 8-937-287-68-88.

*«Хәләл» ашамлыклар кибетенә сатучы. Т. 8-927-442-65-02.

## БИРЕП ТОРЫЛА

*2 бүлмәле фатир, үзәк. Т. 8-937-597-09-44.

*Командировкадагыларга сәгатьләп, тәүлекләп фатир. Т.: 8-927-456-05-69, 8-927-402-35-86.

*Массаж ясый торган кабинет. Т. 8-927-406-11-06.

*Тәүлекләп фатир. Т. 8-927-406-11-06.

## РӘХМӘТЕБЕЗ ЧИКСЕЗ

Тормыш иптәшем, әниебез **Мәдинә Шәрифулла кызы Билдановaны** соңгы юлга озатканда кайгыбызны уртаклашкан, авыр чакта рухи һәм матди ярдәм күрсәткән туганнарга, күршеләргә, авылдашларга – һәркемгә олы рәхмәтебезне белдерәбез.

**Тормыш иптәше, балалары.**

*Шашин ур.да 3 бүлмәле фатир. Т. 8-927-457-46-25.

*Тәүлекләп фатир. Т. 8-937-577-51-24.

*Чаллы Башы авылындагы яңа сәүдә үзәгендә арендага сәүдә мәйданчыклары (читлекләр). Т. 8-927-730-66-92.

*Арендага биналар. Т. 8-927-440-31-55.

*1 бүлмәле фатир. Т. 8-927-438-80-42.

*2 бүлмәле фатир, Вахитов ур. Т. 8-927-247-00-80.

## ЮГАЛТУЛАР

*1991 елда Татарстан Республикасы Октябрь районы Яңа Иглай урта мәктәбе тарафыннан Гөлсинә Минталип кызы Мусина исеменә бирелгән урта (тулы) гомуми белем турындагы А серияле №660647 аттестатны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

## АЛМАШТЫРЫЛА

*Йортны – өстәмә түләп, 2 бүлмәле фатирга. Т.: 8-927-422-24-56, 8-937-292-25-68.

**АШЫГЫЧ, ОЕШМАГА КИРӘК:**

- *отделка ясаучылар*
- *сылаучы-буяучылар*
- *төрле эшчеләр*
- *«КамАЗ»га шофер.*

**Түләү яхшы. Т. 9-50-52.**

## Кайгы уртаклашабыз

«Бердәм исәп-хисап үзәге» ОООсы коллективы, **әнисе** вафат булу сәбәпле, Сәмия Әксан кызы Билдановaның, аның якыннары һәм туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.